## Март аенда кояш чыгу, кояш бату һәм намаз уку вакытлары

| Көннәр | Иртәнге намаз | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Кояш бата Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 5.57 | 7.27 | 13.05 | 16.23 | 18.20 | 19.50 |
| 2 | 5.55 | 7.25 | 13.05 | 16.24 | 18.22 | 19.52 |
| 3 | 5.53 | 7.23 | 13.05 | 16.26 | 18.24 | 19.54 |
| 4 | 5.53 | 7.23 | 13.05 | 16.26 | 18.24 | 19.54 |
| 5 | 5.51 | 7.21 | 13.05 | 16.28 | 18.25 | 19.55 |
| 6 | 5.46 | 7.16 | 13.05 | 16.31 | 18.29 | 19.59 |
| 7 | 5.44 | 7.14 | 13.05 | 16.33 | 18.31 | 20.01 |
| 8 | 5.41 | 7.11 | 13.05 | 16.34 | 18.33 | 20.03 |
| 9 | 5.39 | 7.09 | 13.05 | 16.36 | 18.35 | 20.05 |
| 10 | 5.37 | 7.07 | 13.05 | 16.37 | 18.37 | 20.07 |
| 11 | 5.37 | 7.07 | 13.05 | 16.37 | 18.37 | 20.07 |
| 12 | 5.34 | 7.04 | 13.05 | 16.39 | 18.39 | 20.09 |
| 13 | 5.29 | 6.59 | 13.05 | 16.42 | 18.42 | 20.12 |
| 14 | 5.27 | 6.57 | 13.05 | 16.44 | 18.44 | 20.14 |
| 15 | 5.25 | 6.55 | 13.05 | 16.45 | 18.46 | 20.16 |
| 16 | 5.22 | 6.52 | 13.05 | 16.47 | 18.48 | 20.18 |
| 17 | 5.20 | 6.50 | 13.05 | 16.48 | 18.50 | 20.20 |
| 18 | 5.17 | 6.47 | 13.05 | 16.50 | 18.51 | 20.21 |
| 19 | 5.17 | 6.47 | 13.05 | 16.50 | 18.51 | 20.21 |
| 20 | 5.13 | 6.43 | 13.05 | 16.52 | 18.55 | 20.25 |
| 21 | 5.10 | 6.40 | 13.05 | 16.54 | 18.57 | 20.27 |
| 22 | 5.08 | 6.38 | 13.05 | 16.55 | 18.59 | 20.29 |
| 23 | 5.05 | 6.35 | 13.05 | 16.57 | 19.00 | 20.30 |
| 24 | 5.03 | 6.33 | 13.05 | 16.58 | 19.02 | 20.32 |
| 25 | 5.01 | 6.31 | 13.05 | 17.00 | 19.04 | 20.34 |
| 26 | 4.58 | 6.28 | 13.05 | 17.01 | 19.06 | 20.36 |
| 27 | 4.56 | 6.26 | 13.05 | 17.02 | 19.08 | 20.38 |
| 28 | 4.53 | 6.23 | 13.05 | 17.04 | 19.10 | 20.40 |
| 29 | 4.51 | 6.21 | 13.05 | 17.05 | 19.11 | 20.41 |
| 30 | 4.49 | 6.19 | 13.05 | 17.06 | 19.13 | 20.43 |
| 31 | 4.46 | 6.16 | 13.05 | 17.08 | 19.15 | 20.45 |

*Намаз вакытлары турында мәгълүматларны Самара өлкәсе мөселманнарының Региональ Диния нәзарәте хезмәткәрләре әзерләде, мөфти Талип хәзрәт ЯРУЛЛИН раслады. Җомга көннәре аерып күрсәтелгән.*

**Учредители: трудовой коллектив редакции газеты «Бердэмлек» и Региональное Духовное управление мусульман Самарской области.**

**Оештыручылар: «Бердәмлек» газетасы редакциясенең хезмәт коллективы һәм Самара өлкәсе мөселманнарының Региональ Диния нәзарәте.**

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

# КЫЙБЛА

„БЕРДӘМЛЕК" ГАЗЕТАСЫНЫҢ АЙЛЫК ДИНИ КУШЫМТАСЫ

№ 2
2013 ел
февраль

№ 9 (1188), 23 февраль 2013 ел

*ВӘГАЗЬ*

## Коръән укуның әҗерен багышлау

Һәр изге гамәл өчен - намазмы ул, уразамы, хаҗ кылумы, садакамы, Коръән укумы - кеше кемгә тели, шуңа әҗер бирә ала. Бирелгән әҗер үлгән кешегә барып җитәчәк, һәм сөннәт кешеләре әйтүенчә, мәрхүм моннан файда ала. Коръән укудан вафат булган кеше әҗер алмый, дип игълан итүче хаклы түгел һәм аны тыңларга ярамый. Мәрхүмнәрнең исәннәр биргәнне алуын Аллаһыны танып-белгән күп кешеләр (гарифун) раслыйлар. Мондый мисаллар күп, аларның берничәсен китерәм. Рабига әл-Гәдәвийә исеме күпләргә таныш. Үзенең изгелеге һәм Аллаһыга ихлас хезмәт итүе белән танылган хатынны шулай атаганнар. Ул үлгәннән соң, бер яхшы кеше аны төшендә күргән. Ул аның өчен Аллаһыдан бик күп сораган. Төшендә бу хатын аңа: «Синең бүләгеңне миңа нурдан торган һәм ефәк яулык белән капланган подноста алып киләләр», – дигән.

Ибн Габдессаләм исемле бер бөек дин белгече исән кеше тарафыннан укылган Коръәннең әҗере үлгән кешегә барып җитмәвен әйткән. Ул үлгәннән соң, аны төшендә күрүче: «Хәзер нәрсә әйтерсең, үлгән кешегә әҗер биреләме, юкмы?» – дип сораган. Ул: «Аллаһы белән ант итәм, мин ялгышканмын, бирелә икән шул», дигән.

Мәрхүмнәргә файда булмый, дип әйтүчеләргә түбәндәге аятьтән башка дәлил юк. Бу аятьнең тәфсире башка аять (нәсих) белән бетерелгән.

Беренче аятьнең мәгънәсе шунда: кеше мәңгелек тормышта дөньяви тормышта әзерләгәннән башка һичнәрсәгә ия булмас. Шул рәвешчә, кем изгелек кылса, шул изгелек табар. Кем начарлык кылган, шул начарлыкка тап булыр. Башкалар кылган яхшылык өчен әҗер булмаган кебек, башкалар тарафыннан кылынган явызлык өчен дә җәза юк. Һәркем үзенең эш-гамәлләренә бәйле рәвештә үзенә тиешле әҗер яки җәзаны алыр. Әгәр бу сүзләрне безнең җир тормышына карата кулланcак, болай дип әйтергә була: «Язын нәрсә чәчсәң, көзен шуны урырсың».

Моннан башка кеше биргәнне алу мөмкин түгел дигән мәгънә килеп чыгамыни? Әлбәттә, дөреслек шунда: мин үзем чәчкәннән артыгын җыя алмыйм. Әмма минем башка кеше биргәнне ала алмавым дию дә дөрес түгел. Үлгән кеше Коръән укуның әҗерен ала алмый диючеләр, әгәр үзләре моңа ышана алсалар, исәннәр дә бер-берсенең җибәргән посылкаларын ала алмыйлар, диярләр иде.

Ибн Габбас: «Балалар үзләренең әти-әниләренең изге гамәлләре аркасында җәннәткә әләгә алалар дигән икенче аять моннан алдагы аятьнең хөкемен туктата», - дигән. Әмма белеп торырга кирәк: әти-әниләре аркасында җәннәткә исламнан ерак булган яисә мөртәт булып үлгән балалар кермәячәк. Моны белү бик мөһим.

Икенче аятьнең мәгънәсе түбәндәгедән гыйбарәт: әгәр ата-ана һәм балалары бер мохиттан чыксалар, әгәр бу Аллаһы ихтыярында булып, алар бер-берсен яклый алсалар, шул очракта гына алар бергә җәннәткә керәчәкләр. Яклауның мәгънәсе ярдәм күрсәтүдән гыйбарәт. Яклау хокукына ия булучы кешеләргә Аллаһы, әгәр бу Аның ихтыярында булса, һичшиксез, бер-берсен яклау мөмкинлеге бирәчәк. Без дә шулай ук моңа өметләнәбез. Аңлаган кешеләр өчен әйтәм: Изге Коръәндә һәм Пәйгамбәребезнең хәдисләрендә бу фактны дәлилләүче күп аргументлар бар.

Бер хатын Пәйгамбәрдән: «Минем кечкенә малаем да хаҗ кыла аламы, һәм ул аңа исәпләнәме?» – дип сораган. Пәйгамбәребез: *«Әйе, ул хаҗ кыла ала, һәм син моның әҗерен алачаксың, әмма аның хаҗ кылуы исламның мәҗбүри баганасы буларак исәпләнми»,* - дип җавап биргән.

Икенче бер кеше шулай ук Пәйгамбәргә сорау биргән. Ул: «Минем әнием үлде. Әгәр мин аның өчен садака бирсәм, ул аңа барып ирешерме, һәм моннан аңа файда булырмы?» - дигән. Пәйгамбәребез: *«Синең әниең моның әҗерен алыр, һәм аңа моннан файда булыр»,* - дип җавап биргән.

Әгәр Аллаһыдан укылган намаз, бирелгән садака яки Коръән уку өчен бөтен өммәткә дә әҗерен бирүен сорасаң, бернинди чикләүләрсез барысына да бирелəчәк. Аллаһы